ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**КАРАР**

«15» гыйнвар 2024 ел № 5

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясе мәгълүмат кырының бер квадрат метрын уртача базар бәясен раслау турында**

Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү максатыннан, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, «Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 20 апрелендәге 64 номерлы Арча муниципаль районы Советы карары, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзү хокукына ачык аукцион үткәрү тәртибе турында» 2023 елның 14 октябрендәге 247 номерлы Арча муниципаль районы Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясе мәгълүмат кырының бер квадрат метрын уртача базар бәясен (Р параметры - Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешү буенча түләүнең башлангыч (минималь) күләмен исәпләү тәртибе) кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.М. Хәсәновка йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
15.01 2024 ел, № 5
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә реклама конструкциясе мәгълүмат кырының 1 квадрат метрын уртача базар бәясе күләме**

Р параметрын - реклама конструкциясе мәгълүмат кырының 1 квадрат метрын уртача базар бәясен (үлчәү берәмлеге аена сум) 95 (туксан биш) сум күләмендә билгеләргә.

Бәя «АК ВОСТОК» ҖЧҖнең 2023 елның 26 декабрендә үткәргән 411 номерлы бәяләү турындагы хисабы нигезендә формалаштырылды.